**Кукмара муниципаль районы**
**Оштырма Юмья авыл җирлеге Башлыгы**

**Карары**

**10 ноябрь, 2023 ел** **№ 6**

Җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән куллану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турында» 2004 елның 29 декабрендәге 191-ФЗ номерлы Федераль законның 4 өлешендәге 3 пункты, Оштырма-Юмья авыл җирлеге Уставының 19 статьясы, Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советының 2014 елның «04» февралендәге 1 номерлы карары белән расланган «Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 14 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 11 декабрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Иске Юмья авылы, Мәктәп урамы, 22 адресында урнашкан Оштырма-Юмья авыл башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Югары Юмья авылы, Тау асты урамы, 3 б адресында урнашкан 16:23:040501:62 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «балалар бакчасы» төреннән «шәхси торак төзелеше» төренә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү өчен, түбәндәге составта комиссия төзергә:

- Тимофеев Станислав Валерьевич, Оштырма-Юмья авыл җирлеге башлыгы – комиссия рәисе;
- Степанов Валерий Александрович Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советы депутаты – комиссия әгъзасы;
- Маматов Сергей Михайлович, Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советы депутаты – комиссия әгъзасы.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 422102, ТР, Кукмара районы, Иске Юмья авылы, Мәктәп урамы, 22 йорт (Оштырма-Юмья авыл башкарма комитеты җитәкчесе исеменә).

4. Әлеге карарны Оштырма-Юмья авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Оштырма-Юмья авылы башкарма комитеты җитәкчесе:** **С.В. Тимофеев**